**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 20 июнендәге 1860 номерлы карары**

**Казан шәһәре администрациясе башлыгының 2005 елның 23 мартындагы 650 номерлы «Гражданка Р.Г.Маннановага Урожайный тыкрыгы, 15 адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген бирү турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

Россия Федерациясе Җир кодексының 48 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Җәләева Надежда Георгиевнаның гаризасы нигезендә, ачык сервитут билгеләнгән җәмәгатьчелек ихтыяҗлары булмау сәбәпле, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре администрациясе башлыгының 2005 елның 23 мартындагы 650 номерлы «Гражданка Р.Г.Маннановага Урожайный тыкрыгы, 15 адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген бирү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә, 2 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга.

2. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карар нигезендә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**